**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАЛАННЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ VII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 106**

Баланлы ав. 23 август 2026 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның «29» 08 № 42 Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге советы **КАРАР БИРДЕ:**

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның «29» август № 42 Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының беренче утырышы тулы хокуклы составта уздырылган көннән туктатыла»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Гизетдинов Д.М.